Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №103 (7276) | 27 август, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен

## СССР Югары Советы сессиясе ачылды

МӘСКӘҮ (ТАСС). 26 августта Кремльдә СССР Югары Советының чираттан тыш сессиясе эшен башлады. Палаталарның берләштерелгән иртәнге утырышын Союз Советы рәисе И. Д. Лаптев ачты. Парламент СССР халык депутатларының чираттан тыш съездын 2 сентябрьдә чакырырга карар бирде.

Депутатлар сессиянең көн тәртибен расладылар. Бу документ нигезендә СССР Президенты М. С. Горбачевның дәүләт перевороты белән бәйле рәвештә илдә килеп туган ситуация турында белдерүе күздә тотыла. Сессиядә шулай ук СССР Югары Советы җитәкчелегенең, СССР Югары Советының аерым комитетларының, СССР дәүләт органнарының һәм җәмәгать оешмаларының күптән түгел булып үткән вакыйгалардагы роле турында, мондый ситуацияләр кабатлануга юл куймый торган кичектергесез чаралар һәм закон актлары турында, СССР Министрлар кабинетына ышаныч турында, дәүләт переворотының сәбәпләрен һәм шартларын тикшерү буенча парламент комиссиясе төзү турындагы мәсьәләләрне тикшерү билгеләнде. Депутатлар башка кайбер мәсьәләләрне карауны да тәкъдим иттеләр.

Сессия эшен дәвам итә.

## ИЛДӘГЕ ХӘЛ ТУРЫНДА

СССР Президенты М. С. Горбачев үз өстеннән КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре вәкаләтләрен төшерү турында белдерде. «Секретариат, КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы дәүләт переворотына каршы чыгыш ясамады, Үзәк Комитет аны гаепләү һәм каршы тору позициясенә баса алмады, коммунистларны конституцион законлылыкны бозуга каршы көрәшкә күтәрмәде. Заговорга катнашучылар арасында партия җитәкчелеге членнары да бар», —диелә бу белдерүдә. Шул ук вакытта партиянең күп членнары заговорчылар белән хезмәттәшлектән баш тарттылар, переворотны гаепләделәр һәм аңа каршы көрәшкә кушылдылар. Барлык коммунистларны рәттән гаепләргә берәүнең дә мораль хокукы юк, дип ассызыклады М. С. Горбачев.

СССР Президенты СССР Кораллы Көчләрендә, хокук саклау органнарында һәм дәүләт аппаратында сәяси партияләрнең һәм сәяси хәрәкәтләрнең эшчәнлеген туктату турында, КПСС мөлкәте турында, СССР Министрлар кабинеты турында указлар кабул итте. СССР Югары Советы алдына СССР Министрлар кабинетына ышаныч турындагы мәсьәлә куелды. Республикалар белән берлектә илнең халык хуҗалыгын оператив идарә итүне оештыру өчен И. С. Силаев җитәкчелегендә комитет төзелде.

СССР Президенты указлары белән Д. Т. Язов СССР Оборона министры вазифаларыннан, А. А. Бессмертных СССР Тышкы эшләр министры һәм СССР Куркынычсызлык Советы члены вазифаларыннан азат ителде. СССР Оборона министры итеп Е. И. Шапошников, СССР Эчке эшләр министры итеп В. П. Баранников, СССР Дәүләт иминлеге комитеты рәисе итеп В. В. Бакатин билгеләнде. Бу карарлар СССР Югары Советы сессиясе каравына кертелде.

Компетентлы чыганаклардан СССР Югары Советы рәисе А. И. Лукьяновның отставка соравы мәгълүм булды.

РСФСР Президенты Б. Н. Ельцин РСФСР Коммунистлар партиясе эшчәнлеген туктату турында, партия архивлары турында, СССР дәүләт иминлеге архивлары турында, РСФСР дәүләт власте һәм идарәсе органнарын хөкүмәт элемтәсе белән тәэмин итү турында, Эстония республикасының дәүләт бәйсезлеген тану турында, Латвия республикасының дәүләт бәйсезлеген тану турында указлар кабул итте.

Мәскәүдә Кремльдә РСФСР Президенты резиденциясе өстендә һәм РСФСР Советлар йорты өстендә РСФСР дәүләт флагы күтәрелде. РСФСР Югары Советы, РСФСР Президенты карарлары нигезендә республика дәүләт флагы булып Россиянең тарихи флагы санала. Ул өч тигез зурлыктагы горизонталь полосалы полотнодан тора: өске өлеше ак, уртасы—зәңгәр, асты—кызыл төстә. Флагның киңлеге һәм озынлыгы чагыштырмасы 1:2.

УССР Югары Советы чираттан тыш сессиясендә Украинаның бәйсезлеген һәм мөстәкыйль Украина дәүләте—Украина төзелүен игълан итте. Бәйсезлек игълан ителгән актны раслау турында 1991 елның 1 декабрендә республика референдумы үткәрү турында карар кабул ителде. Белоруссиянең дәүләт бәйсезлеге турында закон бу республика Югары Советы сессиясендә кабул ителде.

19—21 августтагы вакыйгаларның нәтиҗәләрен бетерү һәм бәлага юлыгучыларга материаль ярдәм күрсәтү өчен РСФСР Министрлар Советының бюджеттан тыш фонды оештырылды. Ирекле взнослар түбәндәге счетка күчерелә: 700501 МФО 191027 в ОПРУ Центрального банка РСФСР.

Мәскәүдә переворот көннәрендә РСФСР Советлар йортын саклап һәлак булган Д. Комарьны, И. Кричевскийны, В. Усовны күмүгә багышланган матәм митингы булды.

СССР Президенты Указы белән аларга үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Рәсми чыганаклардан СССР Президентының киңәшчесе маршал С. Ф. Ахромеевның үзен-үзе үтерүе мәгълүм булды.

**(ТАСС).**

### КПСС райкомы һәм район партия оешмасы контроль комиссиясенең чираттан тыш берләштерелгән пленумы турында

## ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

Берләштерелгән пленум эшендә КПСС райкомы членнары һәм район партия оешмасының контроль комиссиясе членнары, башлангыч партия оешмалары секретарьлары катнашты.

Пленум түбәндәге мәсьәләләрне карады.

1. КПССның Октябрь райкомының беренче секретаре вәкаләтләрен өстеннән төшерү турында.
2. КПССның Октябрь райкомын тарату турында.
3. Район партия оешмасының контроль комиссиясен тарату турында.

Пленумда КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. МОРАДЫЙМОВ чыгыш ясады.

Көн тәртибендәге мәсьәләләрне тикшерүдә КПСС райкомы бюросы члены, РОВД начальнигы В. В. ИВАНОВ, район партия оешмасының контроль комиссиясе рәисе Ф. М. ГАЛИМОВ, КПСС райкомы члены, шәһәрнең икенче урта мәктәбе укытучысы Х. Г. ГАФУРОВ, «Норлатнефть» НГДУсы башлангыч партия оешмасы секретаре А. П. ШАМКИН, НУРБ башлангыч партия оешмасы секретаре Н. А. АЛФЕРОВ, Тукай исемендәге махсус хуҗалык башлангыч партия оешмасы секретаре Р. Х. ШӘЙХЕТДИНОВ һәм башка иптәшләр чыгыш ясадылар.

Тикшерелгән мәсьәләләр буенча пленумда тиешле карарлар кабул ителде.

### КПССның Октябрь райкомына

## ГАРИЗА

КПССта килеп туган иҗтимагый-сәяси хәл уңаеннан КПССның Октябрь райкомының беренче секретаре вәкаләтләрен өстемнән төшерү турында белдерүне зарур дип саныйм.

**Х. Морадыймов.**

### КПССның Октябрь райкомының һәм район партия оешмасының контроль комиссиясенең берләштерелгән пленумының 1991 елның 26 август

## КАРАРЫ

Иптәш Х. Х. Морадыймовның гаризасы турында.

КПСС райкомының беренче секретаре иптәш Х.Х. Морадыймовның гаризасын карап, КПССның Октябрь райкомы һәм район партия оешмасының контроль комиссиясенең берләштерелгән пленумы

КАРАР БИРӘЛӘР:

1. Килеп туган иҗтимагый-сәяси ситуациядә вазифаларын башкару мөмкин булмау сәбәпле КПССның Октябрь райкомының беренче секретаре вәкаләтләрен өстеннән төшерү турында иптәш Х. Х. Морадыймовның гаризасын канәгатьләндерергә.

### КПССның Октябрь райкомының һәм район партия оешмасының контроль комиссиясенең берләштерелгән пленумының 1991 елның 26 август

## КАРАРЫ

КПССның Октябрь райкомын тарату турында.

1991 елның 19 августында илдә бер төркем дәүләт кешеләре тарафыннан дәүләт переворотын башкаруга омтылыш булды. Бу җинаятьчел хәрәкәтләрдә һәм ГКЧПның конституциягә каршы карарларын яклауда КПССның кайбер членнары, шул исәптән Секретариаты һәм Үзәк Комитеты членнары да катнашты. Бу катлаулы шартларда КПССның республика комитеты да көтеп тору тактикасына басты. Моның белән партиянең җитәкче органнары үзләрен дискредитацияләделәр һәм конституцион тәртипләрне, демократик реформаларны һәм халык ихтыяҗларын яклап чыгарга тулы сәләтсез икәнлекләрен күрсәттеләр. Бу хезмәт ияләренә һәм КПССның гади членнарына бәя биреп бетергесез әхлакый зыян китерде.

Килеп туган хәлдән чыгып һәм СССР Президенты иптәш М. С. Горбачевның партия органнарын тарату турындагы Мөрәҗәгатенә җавап итеп, КПССның Октябрь райкомы һәм район партия оешмасының контроль комиссиясе

КАРАР БИРӘЛӘР:

1. КПССның Октябрь райкомы, аның бюросын тарату һәм структур подразделениеләренең (бүлекләре, комиссияләр) эшчәнлеген туктатуы турында белдерергә.
2. Башлангыч партия оешмаларына аларның җитәкче органнарының (парткомнар, бюролар) киләчәктәге функцияләре турындагы мәсьәләне һәм сәяси партия буларак КПСС эшчәнлегендә коммунистларның катнашуы яисә катнашмау хокукы турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә.
3. СССР Президенты М. С. Горбачев Указы нигезендә КПСС райкомының административ бинасын, хуҗалык корылмаларын, мөлкәтен, партия архивын халык депутатларының Октябрь район Советына тапшырырга.

### КПССның Октябрь райкомының һәм район партия оешмасының контроль комиссиясенең берләштерелгән пленумының 1991 елның 26 август

## КАРАРЫ

Район партия оешмасының контроль комиссиясен тарату турында.

1991 елның 19 августында илдә бер төркем дәүләт кешеләре тарафыннан дәүләт переворотын башкаруга омтылыш булды. Бу җинаятьчел хәрәкәтләрдә һәм ГКЧПның конституциягә каршы карарларын яклауда КПССның кайбер членнары, шул исәптән Секретариаты һәм Үзәк Комитеты членнары да катнашты. Бу катлаулы шартларда КПССның республика комитеты да көтеп тору тактикасына басты. Моның белән партиянең җитәкче органнары үзләрен дискредитацияләделәр һәм конституцион тәртипләрне, демократик реформаларны һәм халык ихтыяҗларын яклап чыгарга тулы сәләтсез икәнлекләрен күрсәттеләр. Бу хезмәт ияләренә һәм КПССның гади членнарына бәя биреп бетергесез әхлакый зыян китерде.

Килеп туган хәлдән чыгып һәм СССР Президенты иптәш М. С. Горбачевның партия органнарын тарату турындагы Мөрәҗәгатенә җавап итеп, КПССның Октябрь райкомы һәм район партия оешмасының контроль комиссиясе

КАРАР БИРӘЛӘР:

1. Район партия оешмасының контроль комиссиясенең таратылуы һәм эшчәнлеген туктатуы турында белдерергә.

